ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.11.2017ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2849**

Мәктәп укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәп укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативлары турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елның 01 гыйнварыннан балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын расларга(1 нче кушымта).
2. Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәп укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативларын раслау турында» 2016 елның 08 ноябрендәге 3140 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның 1пунктында расланган, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары нигезендә «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Җитәкчесе урынбасары-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 13 декабрендәге
2849 номерлы карарына.
1 нче кушымта

2018 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе
НОРМАТИВЛАРЫ

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километрга узган юлы ставкасы, сум |
| КАВЗ | 104691 | 33,53 |
| ПАЗ | 104948 | 33,52 |
| ГАЗ «Газель» | 99417 | 28,22 |
| УАЗ | 98964 | 27,10 |
| FIAT | 98707 | 26,10 |
| Peugeot Boxer | 99222 | 25,73 |
| Ford Transit | 100046 | 28,11 |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 13 декабрендәге
2849 номерлы карарына.
2 нче кушымта

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмә Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү).

1.2 Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм исәп-хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3 Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе нормативлары ел саен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4 Муниципаль хезмәт күрсәтүне финанслар белән тәэмин итүнең айлык күләме исәп-хисабын формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөреше турындагы мәгълүмат, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләре мониторингы буенча бердәм системаның автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты чикләрендә, автотранспорт чараларының факттагы йөреше турындагы мәгълүматлар буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәп-хисабы

2.1 $i$-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер километрга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы нормасы , сумга;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасы өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру нормативы ставкасы-сум;

$M_m$ - модельнең $m$, берәмлек автотранспорт чаралары саны;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.